| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ | | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА |
|---|---|---|
| 423740,Актаныш авылы,Ленин пр., 17 нче йорт. Тел/факс3-13-44. | | 423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/факс 3-13-44. |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 12. 11. 2019

**КАРАР** ПР-264

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларына саву аппаратлары сатып алган өчен чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында " 2019 елның 19 августындагы ПР-173 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69,78 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларына саву аппаратлары сатып алган өчен чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» гы 2019 елның 19 августындагы ПР-173 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр бирү тәртибенең 2 пунктының 3 пунктчасында 2019 ел өчен саву аппаратларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга «түләү документлары белән расланган» сүзен «расланган түләү документлары белән " сүзенә алмаштырырга»;

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга 2019 елда саву аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең 2 пунктының 4 пунктчасында "кимендә 5 сыер" сүзен " ике һәм аннан күбрәк савым сыеры" сүзләренә алмаштырырга»;

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга 2019 елда саву аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең 2 пунктының 5 пунктчасында " 24 000 (егерме дүрт мең) мең сүзләрен ", "23 000 (егерме өч мең) мең" сүзләренә алмаштырырга";

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга 2019 елда саву аппаратлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең 2 пунктының 7 пунктчасында "8 пунктка туры килүгә" сүзләрен "6 пунктка туры килүгә" сүзләренә алмаштырырга»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен икътисад буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Сираева Л. Р. контрольдә тота.

Җитәкче И. И. Габделхаев